**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 20 июнь № 402

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет учреждениеләренең һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан ассигнованиеләр ала торган башка оешмаларның эшмәкәрлек эшчәнлеге турында» 2004 ел, 31 август, 395 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет учреждениеләренең һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан ассигнованиеләр ала торган башка оешмаларның эшмәкәрлек эшчәнлеге турында» 2004 ел, 31 август, 395 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 11 ноябрь, 487 нче; 2005 ел, 18 май, 218 нче; 2005 ел, 14 июнь, 266 нчы; 2005 ел, 15 сентябрь, 451 нче; 2005 ел, 28 ноябрь, 558 нче; 2006 ел, 02 октябрь, 494 нче; 2007 ел, 20 сентябрь, 478 нче; 2007 ел, 22 ноябрь, 651 нче; 2008 ел, 16 октябрь, 753 нче; 2008 ел, 1 декабрь, 844 нче; 2009 ел, 5 июнь, 368 нче; 2009 ел, 24 июль, 516 нчы; 2009 ел, 31 декабрь, 931 нче; 2010 ел, 19 апрель, 272 нче; 2011 ел, 14 февраль, 104 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыру кысаларында бюджет учреждениеләренең һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан ассигнованиеләр ала торган башка оешмаларның гражданнарга һәм юридик затларга күрсәтә торган хезмәтләре исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

исемендәге «сәламәтлек саклау учреждениеләре» сүзләрен «медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

2.8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8. Вакцинопрофилактика, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Профилактика прививкаларының илкүләм календарен һәм эпидемия күрсәткечләре буенча профилактика прививкалары календарен раслау турында» 2014 елның 21 мартындагы 125н номерлы боерыгы нигезендә

Профилактика прививкаларының илкүләм календаренә кертелгән профилактика прививкалары һәм эпидемия күрсәткечләре буенча прививкалар үткәрүдән тыш.»;

2.1 нче пунктның бишенче абзацында, 2.2 нче пунктның унбишенче абзацында, 2.3 нче пунктның дүртенче абзацында, 2.4 нче пунктның өченче абзацында, 2.5 нче пунктның дүртенче абзацында «учреждениеләре» сүзен «оешмалары» сүзенә алмаштырырга;

2.17 нче пунктның икенче абзацында «сәламәтлек саклау учреждениеләрендә» сүзләрен «медицина оешмаларында» сүзләренә алмаштырырга;

2.27 нче пунктта:

беренче, алтынчы, җиденче абзацларда тиешле килешләрдәге «учреждение» сүзен тиешле килешләрдәге «оешма» сүзенә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «хастаханә учреждениесендә» сүзләрен «медицина оешмасында» сүзләренә алмаштырырга;

2.28 нче пунктта «дәвалау учреждениеләре» сүзләрен «медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

2.39 һәм 2.40 нчы пунктларда «учреждениеләр» сүзен «оешмалар» сүзенә алмаштырырга;

2.42 нче пунктта «сәламәтлек саклау хезмәткәрләре» сүзләрен «медицина хезмәткәрләре» сүзләренә алмаштырырга;

2.44 нче пунктта «учреждениеләрендә» сүзен «оешмаларында» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 2.49 нчы пункт өстәргә:

«2.49. Телемедицина технологияләрен кулланып хезмәтләр күрсәтү.»;

10.4 нче пунктның беренче абзацында «Сәламәтлек саклау учреждениеләре» сүзләрен «Медицина оешмалары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\402.doc